| | |
|---|---|
| СОВЕТ КУГУШЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КҮГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**27 июля 2026 года** с.Кугушево **№45**

Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 24 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, техник хаталарны бетерү максатларында, Күгеш авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1.Зеленодольск муниципаль районының Күгеш авыл җирлеге Советының 2026 елның 02 июнендәге 41 номерлы карары белән расланган Күгеш авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә (Күгеш авыл җирлеге Советының 2026 елның 29 июнендәге 43 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:;

1.1. 5 статьяның 6 өлешендә «статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында» сүзләрен «әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында»сүзләренә алмаштырырга.;

1.2. 8 статьяның 1 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Депутат эшчәнлеге рәвешләре булып:

1) җирлек Советы сессияләре эшендә катнашу;

2) җирлек Советының даими комиссияләре эшендә катнашу;

3) федераль дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларына, барлык оештыру-хокукый рәвештәге оешма җитәкчеләренә, иҗтимагый берләшмәләргә мөрәҗәгать;

4) муниципаль хокукый акт проектын кертү;

5) җирлек Советы тарафыннан кабул ителә торган муниципаль хокукый актлар проектларын эшләүдә катнашу;

6) җирлек Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертелә торган Татарстан Республикасы законнары проектларын әзерләүдә катнашу;

7) депутат гарызнамәсе кертү;

8) сайлаучылар белән очрашулар, аларның мөрәҗәгатьләре белән эшләү, үзе вәкил булган җирлек халкына үз эшчәнлеге һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү;

9) җирле референдумнарны, гавами тыңлауларны, җыелышларны, конференцияләрне һәм гражданнардан сорашып белешүләрне оештыруда һәм уздыруда катнашу;

10) территориаль иҗтимагый үзидарә оештыруда катнашу.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Күгеш авылы, мәктәп яны урамы, 1а йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында (җирлек администрациясе бинасы).

**Күгеш авыл җирлеге башлыгы:** **А.А.Гатауллин**